Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XLV-2**

Балык Бистәсе штп. 2019 елның 24 сентябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2018 елның 4 сентябрендәге "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы депутаты статусы турында Нигезләмәне раслау хакында"гы XXXIII-4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, 2019 елның 26 июлендәге " "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законның 40 маддәсенә һәм "Коррупциягә каршы тору турында" Федераль законның 13.1 маддәсенә үзгәрешләр кертү хакында" 228-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2018 елның 4 сентябрендәге "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы депутаты статусы турында Нигезләмәне раслау хакында"гы XXXIII-4 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2019 елның 1 апрелендәге XLI-5 номерлы карары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 5 маддәнең 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"7.Әлеге маддәнең 6 өлеше нигезендә үткәрелгән тикшерү нәтиҗәсендә 2008 елның 25 декабрендәге "Коррупциягә каршы тору турында" 273-ФЗ номерлы Федераль закон, 2012 елның 3 декабрендәге "Дәүләт вазифаларын биләүчеләрнең һәм бүтән затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүенә контроль турында" 230-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 7 маендагы "Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм ия булуны, наличный акча средстволары һәм хәзинәләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында" 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәмәү, йөкләмәләрне башкармау фактлары ачылганда (беленгәндә), Татарстан Республикасы Президенты тиешле карарны кабул итүгә вәкаләтле җирле үзидарә органына яки судка Совет депутатының вәкаләтләрен вакытыннан алдан туктату яки күрсәтелгән затка карата башка җаваплылык чарасы куллану турында белдерү белән мөрәҗәгать итә.";

1.2) 5 маддәне түбәндәге эчтәлектәге 7.1 пункты белән тулыландырырга:

"7.1. Үзенең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган

балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес яки тулы булмаган мәгълүматлар тапшырган район Советы депутатына, әгәр әлеге мәгълүматларны бозып күрсәтү алай ук җитди булмаса, түбәндәге җаваплылык чаралары кулланылырга мөмкин:

1) кисәтү;

2) депутатны, вәкаләтләре вакыты туктатылганга чаклы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында вазифалар биләү хокукыннан мәхрүм итеп, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органындагы вазифасыннан азат итү;

3) вәкаләтләр вакыты туктатылганга чаклы даими нигездә вәкаләтләрен гамәлгә ашыру хокукыннан мәхрүм итеп, даими нигездә вәкаләтләрен гамәлгә ашырудан азат итү;

4) вәкаләтләре вакыты туктатылганга чаклы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында вазифалар биләүдән тыю;

5) вәкаләтләре вакыты туктатылганга чаклы даими нигездә вәкаләтләр үтәүне тыю.”;

1.3) 5 маддәне түбәндәге эчтәлектәге 7.2 пункты белән тулыландырырга:

“7.2. Район Советы депутатына карата әлеге маддәнең 7.1 пунктында күрсәтелгән җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе Татарстан Республикасы законына ярашлы рәвештә үзидарәлек хокукый акты белән тәгаенләнә.”.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының законлылык, хокук тәртибе, үзидарәлек милке һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Таҗетдинов